**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлегенең Атабай – Әнкәбә авылында гражданнар җыены карары**

4 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлегенең Атабай – Әнкәбә авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Исәк авыл җирлегенең Атабай – Әнкәбә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Атабай-Әнкәбә авылында ял паркын төзекләндерү өчен юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Исәк авыл җирлегенең Атабай – Әнкәбә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Исәк авыл җирлеге башлыгы _________ З.Р. Мөхәмәтҗанова

Халык җыены секретаре _________ З.Н. Хәсәнҗанова